Туган ягымда алтын көз.

Максат: Укучыларның көз турындагы белемнәрен системага китерү, аларны сәнгатьле итеп укырга һәм тасвирлап сөйләргә, табигатьне образлы итеп күз алдына китерергә өйрәтү;

туган як табигатенең гүзәллеген күрә белергә, аның табигатенә ярату тойгысы, күзәтүчәнлек, эстетик зәвык тәрбияләү, балаларны бу матурлыкның кадерен белергә һәм аны сакларга өйрәтү;

көзге байлык үз хезмәт җимешең, икәненә төшендерү;

көзнең матурлыгын рәссамнар кебек үз иҗатыбызда күрсәтә, язучылар кебек сөйләмдә аңлата белергә өйрәтү.

1. Сез, балалар туган ягым көзенең матурлыгын нәрсәдә күрәсез?

   *Көз*

   *Р. Гәрәй.*

   Туган җирем! Җәең үтсә
   Сокланырлык көзең бар...
   Ерак офыкка тоташып
   Дулкынлана уҗымнар.

   Яшел уҗымнар өстенә
   Зәңгәр томан ябылган,
   Каеннарга, әйтерсең лә,
   Сары тәңкә тагылган.

   Көз атлый инде сыенып
   Печән кибәннәренә
   Тик һаман яз шаулый кебек

Мәктәп тирәләрендә.

Көз ул гүя бакчаларга
Соңгарак калып килә.
Тырыш йортларына үзенең
Муллыгын алып килә.

(Рәсемнәргә игътибар итү)

2.Музыка. Уңыш бәйрәме.

Һәр ел фасылының үзенә генә хас музыкасы, моңы бар

- Сезнеңчә ничек, көз музыкасы, сентябрь аенда ничегрәк булыр?
  ( күңелле, бәйрәмчә)

  Чөнки бөтен нәрсә мул итеп өлгергән, игеннәр җыелган – моннан да зур бәхет буламы соң? Төрле төстәге салават күперенең ачык төсләре, мул уңышы белән шатландыра.

  Чыннан да бу көй бездә иң матур мизгелләрне искә төшерергә, көзге табигатьнең матурлыгын бер-бер артлы күз алдына китерергә ярдәм итә.

3.-Әйдәгез, иң матур сүзләрне кулланып, үзебезгә охшаган шигырьләрне сөйләп, көзнең матурлыгын күрсәтергә тырышыйк әле.

Яфраклы сукмаклардан
Әкрен атлап көз килә.
Сары күлмәген киеп
Агачларга төс бирә.
Ә инде көзге урманга барып эләксәң...
-Сезнең көзге урманда булганыгыз бармы?

Андагы гүзәллеккә сокланып туя алмыйсың. Әйтерсең, аллы-гөлле палас өстенә басып, әкият дөньясына эләгәсең. Урман салават күпередәй төрледән-төрле төсләргә буяла.

Укучы:

*Кайчан гына*

Кайчан гына җәй иде дә,
Тирә-юнь яшел иде
Болыннарда шау чәчәкләр
Күкләрдә яшен иде.

Хәзер агачларның
Җиләнен салган чагы
Газиз җир-ананың тирән
Уйларга талган чагы.

Әгәр без табигатьне күзәтмәсәк, өйрәнмәсәк, Җир-Анабызның гүзәллеген саклый белмәсәк, ул безне гафу итмәс.

4. Табигать белән бергә булу, аны күрү, аның белән сөйләшә алу – бәхет ул.

Бүген без сезнең белән нәкъ шушыларны истә тотып, үзебезнең күзәтүләребездән, эшләгән иҗади эшләребездән чыгып, көзге табигатьнең үзенә генә хас матурлыгын рәссамнар кебек үз иҗатыбызда күрсәтә, шагыйрьләр, язучылар кебек сөйләп аңлата алсак, без инде максатыбызга ирешкән булырбыз.

Яратам мин сары төсне
Бөтен дөнья сары төсле –

Саргайган яфраклар җиргә

Сарылалар сак кына...

Сары була белә шулай

Безнең туган як кына.

5.Илүзә, гаиләгез белән эшләгән эшегез турында берничә сүз әйтмәссеңме икән?

(Көзге паркның матурлыгын чагылдырырга теләгән)

Әйдәгез инде бергәләп шул паркта ял итик.

(кырмыскалар биюе)

Көз көнендә урман,

Кырлар алтын була

Яфраклар да сары

Кызыл ялкын була.

6.Яфраклар коела. Җәйнең җәй буена яфраклар, кояшта кызынып, көзгә таба алтынсу төскә керәләр, коелалар.

Сезнең барыгызга да, яфраклар коелганын, күзәтергә туры килгәне бар. Җил малае белән шаяралар, уйныйлар, җиргә төшкәннәренә үкенмиләр.

Алар тиеннәр кебек ботактан-ботакка сикерешәләр, җирдә уйный-уйный куышалар.

Яфраклар кыштырдыйлар, шыбырдыйлар, очалар, йөгерәләр, йөзәләр.

*Яфрак ява*

Күк зәп-зәңгәр диңгез кебек,

Әйтерсең лә чыңлый һава.

Тирбәлешкән күбәләктәй,

Җир өстенә яфрак ява.

Яфраклар да безнең кебек
Шатланалар, биешәләр,
Өйтерсең лә көлешәләр,
Кыштыр, кыштыр килешәләр
Сикерә, сикерә йөгерешәләр.
Зәңгәр һава, һава
Җир өстенә яфрак ява.

7. Муллык көзе. Шигырьләр сөйләү.

8. Физкульминут.

*Көз*

-И, балалар, күрегез:

- Тышта әнә килде көз

- Әйе, әйе күрәбез.

Көз килгәнен беләбез.

(басалар һәм парта араларыннан чыгалар)

-Я әйтегез, сөйләгез

Ничек килә икән көз?

(кулларны як-якка җәеп болгыйлар)

-Кошлар очты көньякка,

Канат кагып еракка.

( иелеп кулларын идәнгә тидерәләр)

-Аюлар өн казыды

Бик тирән итеп базны.

(Кулга-кул тотынышалар)

-Балыклар да тындылар

Су төбенә чумдылар.

(тотынышкан килеш як-якка чайкалалар)

Агачлар ялангачлар

Җилләрдә тирбәләләр.

Әйе, агачлар – яфраклары, кошлар – туган яклары белән хушлашалар.

9. Музыка. Менә монда инде көзнең музыкасы да үзгәрә. Килешәсезме?

Моңсу, уйландыра торган.

Ул кошларның моңсу тавышлары, еракларга китеп барышлары.

Канатларын җилпиләр, әйтерсең безнең белән саубуллашалар.

Без дә кулъяулык болгап, хәерле юл теләп калабыз.

10. Инсц. Сау булыгыз торналар.

11. Җәнлекләр тормышы үзгәрә.

Октябрь ае. Төсләр үзгәрә торган ай. Нинди җәнлекләрне очратырга була?

Тиеннәрне (кызларны тыңлыйк әле)

Алар буш кул белән килмәгәннәр. Серле чикләвекләр белән сыйларга уйлаганнар.

Биремнәрнең берничәсе тыңлана.

Әйе, табигать юмарт, син дә ярат, сакла, дусты бул! Табигать биргән байлыкның кадерен бел!

Ф. Яруллин.

Әткәм кебек тырыш көз,

Әнкәм кебек юмарт көз.

Көзләр юмарт булганга

Бик бәхетле бик шат без.

12. Йомгаклау.

Никтер моңсу, нидер юк

Күңел түре буш кебек

Әмма шыклап тутырган

Амбар, базларны күреп,

Буш урынга тиз генә

Шатлык тулып өлгерә.

Ә шат яшәргә җирдә

Хыялланмый кем генә.